КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 август г.Казань № 1003

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче; 2020 ел, 6 июль, 555 нче; 2021 ел, 21 апрель, 268 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2022 ел, 12 декабрь, 1316 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1493 нче; 2023 ел, 1 март, 195 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 13 июль, 823 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү

тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

VI бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VI. Комплекслы үзәкләрнең көндезге бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә өлкән яшьтәге гражданнарга, инвалидларга һәм 14 яшьтән һәм аннан зуррак инвалид балаларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе»;

6.1.1 пунктның таблицасында:

4 пунктның 2 нче графасында «инвалид» сүзеннән соң «(инвалид бала)» сүзләрен өстәргә;

8 пунктның 2 графасына «****» астөшермә билгесен өстәргә;

«**» астөшермәсендә «инвалид» сүзеннән соң «(инвалид бала)» сүзләрен өстәргә;

астөшермәләргә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«*****инвалид балаларны хезмәт күрсәтүгә алганда тапшырылмый.»;

6.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2.1. Көндезге бүлекләрдә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүләр гражданнарга түләүсез яки түләүле яисә өлешчә түләүле (гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турындагы федераль законнар нигезендә һәм бу Тәртипнең I бүлегендәге 1.5 бүлекчәсе нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә торган күләмдә) күрсәтелә.

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларга көндезге бүлекләрдә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр түләүсез күрсәтелә.»;

6.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.4.1. Комплекслы үзәкләрнең көндезге бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә өлкән яшьтәге гражданнарга, инвалидларга һәм 14 яшьтән һәм аннан зуррак инвалид балаларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исеме, аларның тасвирламасы һәм күләмнәре, аларны күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре һәм аның нәтиҗәләрен бәяләү әлеге Нигезләмәнең 5 нче кушымтасында китерелде.»;

6.4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«интеллекты бозылган, аутистик спектрдагы бозылышлары булган 14 яшьтән һәм аннан зуррак инвалид балаларга.»;

6.4.3 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымтада:

«2020 – 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектында катнашучы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең көндезге бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исеме, аларның тасвирламасы һәм күләмнәре» таблицасында:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексны үзәкләренең көндезге бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә өлкән яшьтәге гражданнарга, инвалидларга һәм 14 яшьтән һәм аннан зуррак инвалид балаларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исеме, аларның тасвирламасы һәм күләмнәре»;

«Социаль-көнкүреш хезмәтләре» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 1.3 һәм 1.4 пунктлар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «1.3. | Туклану белән тәэмин итү | Көндезге бүлектә социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның туклануын оештыру | ашату | социаль хезмәт күрсәтү чорында тәүлеккә 1 тапкыр |
| 1.4. | Транспорт белән алып баруны оештыру | Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларны социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүченең автотранспорты белән көндезге бүлеккә алып бару (һәм көндезге бүлектән өйгә алып кайту) | транспорт белән йөртү | социаль хезмәт күрсәтү чорында көнгә 2 тапкыр»; |

«2020 – 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектында катнашучы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең көндезге бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре һәм аның нәтиҗәләрен бәяләү» таблицасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексны үзәкләренең көндезге бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә өлкән яшьтәге гражданнарга, инвалидларга һәм 14 яшьтән һәм аннан зуррак инвалид балаларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре һәм аның нәтиҗәләрен бәяләү».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин